ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.10.2024 г.Казань № 293-8/тко-2024

Лениногорск муниципаль районының «Благоустройство и Озеленение» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тариф билгеләү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 02.10.2024 ел, № 21-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Лениногорск муниципаль районының «Благоустройство и Озеленение» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә әлеге карар кушымтасына туры китереп чик дәрәҗә тариф билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән чик дәрәҗә тариф әлеге карар үз көченә кергән көннән башлап 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Лениногорск муниципаль районының «Благоустройство и Озеленение» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 109 номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, җайга салу чорына тариф билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының
02.10.2024 № 293-8/тко-2024 карарына кушымта

«Благоустройство и Озеленение» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тариф

| Т/с | Муниципаль берәмлек, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тариф, сум/тонна |
|---|---|---|
| | | 02.10.2024 № 293-8/тко-2024 карар үз көченә кергән көннән башлап 2024 елның 31 декабренә кадәр |
| | Лениногорск муниципаль районы | |
| 1 | "Төзекләндерү һәм яшелләндерү" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 1 144,21 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге